Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы
Габдрахман авыл Советы

КАРАРЫ

№ 82 11 декабрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл Советының 2018 елның 27 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл башкарма комитеты нигезләмәсе турында»гы 56 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә

Габдрахман авыл Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл Советының 2018 елның 27 ноябрендәге «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Габдрахман авыл башкарма комитеты нигезләмәсе турында»гы 56 номерлы карары кушымтасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3 бүлекне төшереп калдырырга;

1.2. 4 бүлектә:

1.2.1. 4.1 пунктының 4 пунктчасының өченче абзацында «торак биналарны үзгәртеп планлаштыру» сүзләрен «күпфатирлы йорттагы биналарны үзгәртеп планлаштыру» сүзләренә алмаштырырга;

1.2.2. 4.1 пунктының 4 пунктчасының бишенче абзацын төшереп калдырырга;

1.2.3. 4.1 пунктының 6 пунктчасының уникенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«-каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнаша;»;

1.2.4. 2 пунктны 4.2 пункты дип санарга;

1.2.5. 4.2 пунктының унөченче абзацында «күзәтүчесез хайваннарны тоту һәм карап тоту буенча чаралар» сүзләрен "хуҗасы булмаган хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлек" сүзләренә алмаштырырга;

1.2.6. түбәндәге эчтәлектәге унбишенче, уналтынчы абзацлары өстәргә:

«-1992 елның 7 февралендәге «-кулланучылар хокукларын яклау турында» 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законында каралган кулланучылар хокукларын яклау чараларын гамәлгә ашыра»;

«-Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә, үзирекле корылманы сүтү, үзирекле корылманы сүтү яки аны билгеләнгән таләпләргә туры китерү турында карарлар кабул итә.».

1.2.7. 3 пунктны 4.3 пункты дип санарга;

1.2.8. түбәндәге эчтәлектәге 4.4 - 4.7 пунктлары өстәргә:

«4.4. Җирлекнең башкарма комитеты җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәүне федераль законнар,

җирлек Советы карарлары, җирлек башлыгы карарлары һәм күрсәтмәләре нигезендә тәэмин итә.

4.5. Җирлекнең башкарма комитеты җирле үзидарә органнарына федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән тапшырылган аерым дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашыра.

4.6. Җирлекнең башкарма комитеты, әгәр бу федераль законнарда каралган булса, башка дәүләт вәкаләтләрен гамәлгә ашырырга, шулай ук башка муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнары, дәүләт хакимияте органнары компетенциясенә кертелмәгән, федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары белән үз компетенцияләреннән төшереп калдырылмаган башка мәсьәләләрне, Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларыннан бирелгән бюджетара трансфертлардан һәм түләүләрнең өстәмә нормативлары буенча салым керемнәреннән тыш, җирле бюджетлар керемнәре исәбенә хәл итәргә хокуклы.

4.7. Җирлекнең башкарма комитеты үз вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыруны Россия Федерациясе Бюджет кодексы нигезендә Әлмәт муниципаль районы бюджетына Җирлек бюджетыннан бирелә торган бюджетара трансфертлар исәбеннән Әлмәт муниципаль районының җирле үзидарә органнары белән килешү төзергә хокуклы.».

2. Әлеге карарны Габдрахман авылы Совет урамы 77 йорт территориясендә урнашкан махсус мәгълүмат стендларында игълан итәргә; «Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында «Интернет» челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны авыл җирлеге башлыгына йөкләргә.

Габдрахман
авыл җирлеге башлыгы Р.Ш.Мотаһиров